ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня,
Зеленодольский район, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНЭ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная ур., 5, Бишнэ ав,
Зеленодольск районы., 422528

# **КАРАР**

2020 елның 30 сентябре №38

"Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 23 апрелендәге 14 номерлы «Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне җайга салу максатларында һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында»гы 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты, Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ**:

1. Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 23 апрелендәге 14 номерлы «Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең вазыйфаи окладының күләме (ул 11 498 сум тәшкил итә) берничә тапкыр исәпләнә;

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион

сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы).

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен үзем контрольдә тотам.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы:** **И.М.Фатхуллин**